**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге составына керүче Суровка авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**
**КАРАР**

15 ноябрь, 2023 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 14 нче, 15 нче ноябрендә узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре белән түбәндәге мәсьәлә буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

1. «2024 елда яшәү урыны буенча Новотроицк авыл җирлеге Суровка авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 (бер мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләргә, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, аларның гаилә әгъзаларын үзара салым буенча түләүдән азат итәргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә, Сез ризамы:

1) Кече архитектура формаларын сатып алу һәм урнаштыру;

2) Юлларны ремонтлау (вак таш, ком, асфальт валчыгы сатып алу);

3) Электроматериаллар сатып алу, урам яктырту челтәрләрен монтажлау һәм урнаштыру;

4) Суровка авылының сууткәргеч трассасында янгын гидрантларын урнаштыру;

5) Новотроицкое авылының Космонавтлар урамына борылыштан алып Суровка авылының Чехов урамына кадәр тротуар буйлап эрегән һәм яңгыр суын дреннаж белән чистарту.

ӘЙЕ ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 1333 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 759 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 759 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге Суровка авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. «2024 елда яшәү урыны буенча Новотроицк авыл җирлеге Суровка авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 (бер мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләргә, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, аларның гаилә әгъзаларын үзара салым буенча түләүдән азат итәргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә, Сез ризамы:

1) Кече архитектура формаларын сатып алу һәм урнаштыру;

2) Юлларны ремонтлау (вак таш, ком, асфальт валчыгы сатып алу);

3) Электроматериаллар сатып алу, урам яктырту челтәрләрен монтажлау һәм урнаштыру;

4) Суровка авылының суүткәргеч трассасында янгын гидрантларын урнаштыру;

5) Новотроицкое авылының Космонавтлар урамына борылыштан алып Суровка авылының Чехов урамына кадәр тротуар буйлап эрегән һәм яңгыр суын дреннаж белән чистарту.

3. Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге Суровка авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

4. Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге Суровка авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Новотроицк авыл җирлеге Башлыгы Д.М. Габделхәева